КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 9 февраль г.Казань № 83

Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $4^1$ өлеше, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 9 февраль, 83 нче
карары белән расланды

Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең
төбәк комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Әлеге Тәртип халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләрен (алга таба шул ук эзлеклелектә – төбәк комплекслы планы, Тәртип), аның максатларын һәм гамәлдә булу срогын билгели.

2. Төбәк комплекслы планын эшләү максатлары:

автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гомуми файдаланудагы транспортның (тимер юл, һава, су транспорты һәм урам юлыннан йөрми торган транспорт) башка төрләре (алга таба – транспортның башка төрләре) белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу белән үзара бәйләнештә оештырганда Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өстенлекләрен, максатларын һәм бурычларын билгеләү;

халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итә торган чараларны билгеләү, әлеге чараларны гамәлгә ашыру сроклары;

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 220-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) компетенциясенә оештырылуы кертелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны үстерү чаралары исемлеген билгеләү.

3. Төбәк комплекслы планы түбәндәге өстенлекләрне һәм бурычларны үтәүдән чыгып формалаштырыла:

1) Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше, социаль-икътисадый һәм транспорт үсешен интеграцияләү;

2) пассажирлар йөртү иминлеген тәэмин итү;

3) транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында каралган автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында (алга таба – даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты) Татарстан Республикасындагы халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасы территориясендә бердәм тариф сәясәтен

формалаштыру;

5) маршрут транспорт чараларының классларын һәм төрләрен нигезле сайлап алу һәм куллану;

6) шәхси автотранспорт белән гамәлгә ашырыла торган пассажирлар йөртүне гомуми файдаланудагы транспортка күчерү өчен шартлар тудыру;

7) төрле транспорт төрләренең нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итү, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларының нигезсез кабатлануын бетерү;

8) юл хәрәкәтендә маршрут транспорт чаралары хәрәкәтенең өстенлеген тәэмин итү;

9) халыкның күчеп йөрүен һәм пассажирлар йөртү күләмнәрен исәпкә алу;

10) халыкның гомуми файдаланудагы транспорт эше турында хәбәрдар булуын (шул исәптән пассажирларга даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында транспорт чаралары хәрәкәте турында реаль вакыт режимында мәгълүмат бирү юлы белән) тәэмин итү;

11) маршрут транспорт чараларын диспетчерлаштыру һәм навигацияләү, аларның эшен һәм хәрәкәт расписаниеләрен координацияләү, аларның хәрәкәте даими булуын контрольдә тоту;

12) транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында билгеләнгән күрсәткечләрнең максатчан зурлыкларына ирешүне мониторинглау;

13) пассажирлар транспортында һәм тиешле сервисларда интеллектуаль транспорт системасын, шул исәптән әлеге пунктның 7 – 12 пунктчаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында булдыру һәм (яки) үстерү.

## II. Төбәк комплекслы планын әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәртибе

4. Төбәк комплекслы планын әзерләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планнарын төзү методикасын раслау турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1983 номерлы карары белән расланган халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планнарын төзү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Төбәк комплекслы планын әзерләү, аны килештерү, шулай ук аңа үзгәрешләр кертү Министрлык тарафыннан тәэмин ителә.

6. Төбәк комплекслы планын формалаштыру түбәндәге этаплардан тора:

1) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең хәзерге торышын бәяләү;

2) автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, транспортның башка төрләре белән пассажирлар йөртүгә карата пассажирлар йөртү күләмен һәм транспортка ихтыяҗны фаразлау;

3) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең концептуаль вариантларын билгеләү һәм гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган вариантны сайлау;

4) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган варианты чараларын һәм аларны гамәлгә ашыру срокларын билгеләү;

5) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү чараларын һәм Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган вариантының даими рәвештә пассажирлар йөртүне үстерү чараларын финанслау күләмнәрен бәяләү һәм чыганакларын билгеләү;

6) комплекслы планны гамәлгә ашыруны мониторинглау.

7. Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлдәге торышын бәяләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, транспортның башка төрләре белән пассажирлар йөртүгә карата халыкның транспорт хәрәкәтчәнлеге һәм транспортка ихтыяҗ күрсәткечләренә, шул исәптән халыкның яшәү урыннарын, халыкны җәлеп итү объектларын (социаль билгеләнештәге объектларны кертеп) урнаштыруга йогынты ясый торган мәгълүматларны җыю һәм анализлау;

2) халыкның күчеп йөрү ихтыяҗына туры килү-килмәүгә карата даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларының һәм алар составына керә торган тукталыш пунктларының гамәлдәге җыелмасы конфигурациясен анализлау, автовокзалларны, автостанцияләрне, тукталыш пунктларын, автомобиль транспортының һәм шәһәр җир өсте электр транспортының башка объектларын урнаштыру урыннарын билгеләү;

3) халыкның күчеп йөрү ихтыяҗына туры килү-килмәвенә карата транспортның башка төрләре инфраструктурасы конфигурациясен анализлау һәм аның торышын бәяләү;

4) мультимодаль пассажирлар йөртүдә, төрле транспорт төрләре хәрәкәтенең санлы мәгълүматларында һәм сыйфатлы тасвирнамәләрендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, транспортның башка төрләре белән пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның үзара бәйләнешен анализлау;

5) төрле транспорт төрләре белән пассажирлар йөртүнең гамәлдәге күләмнәре һәм структурасы турында мәгълүматларны, йөртүчеләр эше турында мәгълүматларны, маршрут челтәре буенча, шул исәптән вакыт буенча пассажирлар йөртүләр бүленеше турында мәгълүматларны җыю һәм анализлау;

6) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык, куркынычсыз һәм уңайлы булуын тасвирлый торган мәгълүматлар җыю, халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандарты күрсәткечләре зурлыкларын билгеләү һәм аларны анализлау;

7) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлдәге торышының социаль-икътисадый күрсәткечләрен, шул исәптән халыкның хәрәкәтләнү өчен гомуми вакыт чыгымнарын, юл-транспорт һәлакәтләреннән зыянны һәм экологик зыянны исәпләп чыгару;

8) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәлелеген (эреләтеп), шул исәптән даими рәвештә пассажирлар йөртүдән керемнәрне, даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру максатларында субсидияләрне һәм башка финанс ярдәме чараларын, Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлдәге торышының социаль-икътисадый күрсәткечләрен, пассажирлар йөртүгә гомуми чыгымнарны исәпкә алып исәпләп чыгару.

8. Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, транспортның башка төрләре белән пассажирлар йөртүгә карата пассажирлар йөртү күләмен һәм транспортка ихтыяҗны фаразлау түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, транспортның башка төрләре белән пассажирлар йөртүгә карата халыкның транспорт хәрәкәтчәнлеге һәм халыкның транспорт ихтыяҗы күрсәткечләренә йогынты ясый торган күрсәткечләр зурлыклары үзгәрү фаразы;

2) төрле транспорт төрләре арасында пассажирлар йөртү күләмнәре бүленеше фаразы.

9. Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең концептуаль вариантларын билгеләү түбәндәгеләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

автомобиль транспортына һәм шәһәр җир өсте электр транспортына, транспортның башка төрләренә карата пассажирлар йөртү күләме һәм транспортка ихтыяҗ фаразы нәтиҗәләрен;

төрле транспорт төрләре арасында пассажирлар йөртү күләмнәре бүленешен;

автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне транспортның башка төрләре эше белән оештырганда Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү бәйләнешләрен;

Татарстан Республикасында халык күчеп йөрүләренең һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең фараз күрсәткечләре, халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларына хезмәт күрсәтү өчен транспорт чаралары төрен, классын һәм санын сайлап алуны.

Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү вариантларын чагыштыру түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарыла:

халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү зарурлыгын;

Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү тәкъдим ителә торган вариантлары буенча нәтиҗәлелегенең (эреләтеп), шул исәптән даими рәвештә пассажирлар йөртүдән керемнәрне, даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру максатларында субсидияләрне һәм башка финанс ярдәме чараларын, Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлдәге торышының социаль-икътисадый күрсәткечләрен, пассажирлар йөртүгә гомуми чыгымнарны исәпкә алып исәп-хисап нәтиҗәләрен;

планлаштырыла торган финанслау күләмен.

Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган вариантын сайлау Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү нәтиҗәлелегенең исәп-хисапларын, Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең максатчан күрсәткечләре зурлыкларына ирешүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен һәм башка финанслау чыганакларын чагыштыру нигезендә эреләтеп гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителә торган вариантына түбәндәгеләр керә:

220-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) нигезендә Министрлык компетенциясенә оештырылуы кертелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүне үстерү чаралары исемлеге;

программа-аппарат комплексларының, мәгълүматлар алмашу беркетмәләренең һәм форматларының, шулай ук мәгълүмат алмашуда катнашучылар хезмәттәшлеге регламентларының үзара ярашуын тәэмин итү өлешендә Тәртипнең 3 пунктындагы 13 пунктчасында күрсәтелгән пассажирлар транспортында интеллектуаль транспорт системасын, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының транспорт системасын мониторинглауны һәм аның белән идарә итүне гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектларының интеллектуаль транспорт системалары белән аның интеграциясен исәпкә алып булдыру һәм (яки) үстерү чаралары;

даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларының тукталыш пунктларына, автовокзалларга һәм автостанцияләргә, транспортның башка төрләре объектларына халыкны алып килүне тәэмин итә торган транспорт чаралары буларак велосипедларны һәм индивидуаль мобильлек чараларын файдалану мөмкинлекләрен оештыру чаралары;

Татарстан Республикасында халыкка башка транспорт төрләре белән транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планы чаралары исемлеге.

Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган варианты чараларын җентекләп эшләү нәтиҗәләре буенча аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегә даими рәвештә пассажирлар йөртүдән керемне, даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру максатларында субсидияләрне һәм башка ярдәм чараларын, Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү чараларының (шул исәптән халыкның хәрәкәт итүгә гомуми вакыт чыгымнары, юл-транспорт һәлакәтләреннән зыян һәм экологик зыян) социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген, даими рәвештә пассажирлар йөртүгә җыелма чыгымнарны исәпкә алып төгәлләштерелә.

11. 220-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Министрлык компетенциясенә оештырылуы кертелгән даими рәвештә пассажирлар йөртүне үстерү чаралары исемлегенә түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр кертелә:

1) 220-ФЗ номерлы Федераль законда каралган даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары параметрлары турында белешмәләр булган даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату буенча, шулай ук буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү буенча;

2) Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтләр тапшырылган яки яңадан бүленгән очракта, автомобиль транспортының һәм шәһәр җир өсте электр транспортының тукталыш пунктларын, шулай ук төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында, шулай ук федераль һәм (яки) җирле әһәмиятле

автомобиль юлларында шәһәр җир өсте электр транспортының рельс юлларын һәм контакт челтәрләрен урнаштыру һәм җиһазлау;

3) маршрут транспорт чараларына ихтыяҗны, аларны кайтарту срокларын һәм финанслау чыганакларын билгеләү;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртү өчен җайга салына торган тарифларны эшләү һәм (яки) камилләштерү;

5) юл йөрү өчен түләү системасын оештыру һәм камилләштерү, юл йөрү өчен түләүне контрольдә тоту нәтиҗәлелеген арттыру.

12. Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планы чаралары исемлегенә түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр керә:

транспортның башка төрләре белән даими рәвештә пассажирлар йөртү гамәлгә ашырыла торган маршрутларны (аларның параметрларын) билгеләү һәм (яки) үзгәртү;

транспортның башка төрләре белән даими рәвештә пассажирлар йөртү гамәлгә ашырыла торган маршрутларда эксплуатацияләү өчен транспорт чараларына ихтыяҗны, аларны кайтарту срокларын һәм күләмнәрен билгеләү;

транспортның башка төрләренең транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

транспортның башка төрләреннән файдаланып, Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең икътисадый һәм оештыру моделен камилләштерү;

транспортның башка төрләрен үстерү буенча тиешле программалар, планнар һәм башка документлар эшләү яки аларга үзгәреш кертү өчен кирәкле өстәмә чаралар;

әлеге пунктның икенче – алтынчы абзацларында каралган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле транспортның башка төрләрен үстерүне финанслау чыганаклары һәм күләмнәре.

Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру чаралары транспортның башка төрләре үсешен исәпкә алып эшләнә.

13. Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү чараларын һәм Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган вариантының даими рәвештә пассажирлар йөртүне үстерү чараларын финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын бәяләүгә кирәкле финанслау күләмен бәяләү керә, анда әлеге планны гамәлгә ашыру бурычлары, транспортның кайбер төрләре һәм транспорт чаралары төрләре буенча бүлеп, транспорт чараларына (шул исәптән аларны яңартуга) һәм, финанслау чыганакларын күрсәтеп, даими рәвештә пассажирлар йөртү инфраструктурасын үстерүгә бүлеп күрсәтелә.

14. Төбәк комплекслы планы раслана һәм нигезли торган өлешләрдән тора.

15. Төбәк комплекслы планының раслана торган өлеше түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) түбәндәгеләр бирелгән төбәк комплекслы планы паспорты;

исеме;

эшләү өчен нигез;

транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында билгеләнгән күрсәткечләрнең, шул исәптән еллар буенча зурлыгы;

Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү буенча транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында билгеләнгән күрсәткечләрнең максатчан зурлыкларына ирешүне тәэмин итә торган, сайлап алынган өстенлекләрне һәм бурычларның кыскача аңлатмасы;

төбәк комплекслы планын гамәлгә ашыру этапларының исемнәре һәм аларны гамәлгә ашыру сроклары;

финанслауның, шул исәптән төбәк комплекслы планын гамәлгә ашыру этаплары һәм финанслау чыганаклары буенча гомумиләштерелгән күләмнәре;

2) чаралар (чаралар исемлеге);

3) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү чараларын һәм даими рәвештә йөртүләрне үстерү чараларын финанслау планы;

Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү чаралары һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүне үстерү чаралары нәтиҗәлелегенең нәтиҗәләре;

4) график һәм таблица материаллары, аларда түбәндәгеләр бирелә:

маршрут челтәренең сайланган вариант буенча гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган схемасы;

тукталыш (саклана торган, яңадан оештырыла торган, бетерелә торган) пунктларының урнашу урыны;

маршрут челтәрендә һәм вакыт буенча халык хәрәкәтләре һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү күләмнәре бүленеше.

16. Төбәк комплекслы планының нигезли торган өлеше түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү буенча транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк стандартында билгеләнгән күрсәткечләрнең максатчан зурлыкларына ирешүне тәэмин итә торган өстенлекләр һәм бурычлар тасвирламасы;

2) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлдәге торышын бәяләү өчен кулланыла торган материаллар;

3) автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты, транспортның башка төрләре белән даими рәвештә пассажирлар йөртүгә карата даими рәвештә пассажирлар йөртү күләме фаразы һәм транспортка ихтыяҗ нигезләве;

4) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең концептуаль вариантларын билгеләү өчен файдаланыла торган мәгълүматлар;

5) Татарстан Республикасында транспорт хезмәте күрсәтүне үстерүнең концептуаль вариантларын эреләндерелгән бәяләмәсе;

6) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү вариантлары чагыштырмасы;

7) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары параметрлары,

пассажирлар йөртү төрләре, элемтә төрләре, транспорт чаралары типлары, урамнар һәм юллар исемлекләре, тукталыш (шул исәптән беренче һәм соңгы) пунктлары, рейслар озынлыгы, маршрут транспорт чараларының сыйдырышлылык класслары, әйләнеш рейсы вакыты, хәрәкәт расписаниеләре яки интерваллары (тәүлек чорларын, атна көннәрен һәм ел фасылларын исәпкә алып);

8) Татарстан Республикасында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү чараларын һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүләрне үстерү чараларын финанслау күләмнәрен билгеләү өчен кирәкле исәп-хисаплар.

17. Төбәк комплекслы планы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән биш елга раслана.

18. Комплекслы планны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы дәүләт программалары чаралары һәм программага кертелмәгән чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла.

19. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең төбәк комплекслы планының раслана торган өлеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарыла.